Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАРЫ

2018 елның 24 сентябрь № 99

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 24 сентябрендәге 14 номерлы «җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советының 2018 елның 24 сентябрендәге 98 номерлы «җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 18 ноябренә "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"2019 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тәмте авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне башкару өчен көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300,0 сум үзара салым кертү белән килешәсезме:

* Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пунктларда юлларны кышкы карап тоту;
- вак таш түшәлгән юлны ремонтлау: ТатЗОСпоселогы, Үзәк урамы;
* Җирлек территориясен төзекләндерү:
- урамнарны яктыртуны оештыру (электротехник материаллар сатып алу);
* Көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру:
- Тәмте, Лабыш авылларында чүп җыю һәм чыгару.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, 2нче Октябрь урамы, 50 нче йорт. мәдәният йорты бинасы.
- ТР, Кама Тамагы районы, Тәмте авылы, Октябрь урамы 65нче йорт, авыл җирлеге бинасын, шулай ук “Идел таннары” газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кама Тамагы муниципаль районы
Тәмте авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Тәмте авыл җирлеге
Советы Рәисе: И.А. Зиновьев